# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылык турында

Бу Закон этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә хокук бозулар өчен административ җаваплылыкны билгели, дәүләт контролен көчәйтүгә, ялган продукция җитештерү һәм сатуны булдырмауга, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, дәүләт мәнфәгатьләрен саклауны тәэмин итүгә юнәлтелә.

<u>1 статья.</u> Төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр

Алкоголь продукциясенә азык-төлек берәмлеге күләменең бер ярым процентыннан артык этил спирты катнашкан продукция (кондитер эшләнмәләреннән тыш) керә.

Әлеге Законда алкогольле продукция дигәндә күләменең бер ярым процентыннан артыгын этил спирты тәшкил иткән чимал һәм (яисә) ярымфабрикатлар һәм әзер продукция сыйфатында сатуга чыгарылмый торган ярымфабрикатлар аңлашыла.

Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция әйләнеше төшенчәсе аларны читкә чыгару, читтән кайтару, тәэмин итү, сатып алу, саклау, күпләп һәм ваклап сатуны аңлата.

Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне күпләп сату дигәндә юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан җитештерелүче яисә сатып алынучы (кабул итеп алынучы, сатып бирелүче) продукцияне башка юридик затка, шәхси эшмәкәргә яңадан сату (тапшыру, бирү) максатында бирү (сату, тапшыру, шул исәптән уртак эшчәнлек турында килешү нигезендә, комиссия, йөкләмәләр килешүе белән һ.б.) буенча эшкуарлык аңлашыла.

2 статья. Бу Законның гамәлдә булу чикләре

Бу Законда каралган хокук бозулар өчен законнар нигезендә җинаять җаваплылыгы билгеләнмәсә, административ җаваплылык чаралары карала.

Әлеге Закон граждан (физик зат) этикеткалардан, товар билгеләреннән, тамгалардан файдаланмыйча житештергән, сату өчен булмаган алкокольгә һәм алкогольле продукциягә кагылмый.

3 статья. Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция житештерүне һәм әйләнешкә кертүне, саклауны тиешле лицензиясез, шулай ук лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып гамәлгә ашыру

Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тиешле лицензиясез житештергән һәм әйләнешкә керткән өчен -

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең иллеләк алып йөз минималь күләменә кадәр, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең ике йөздән алып өч йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне лицензия таләпләрен һәм шартларын бозып житештергән һәм әйләнешкә керткән өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

Предприятиеләрдә (оешмаларда) этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне лицензиясез саклаган өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар житәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>4 статья.</u> Этил спиртын сатып алуга квотадан һәм Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкогольле продукциягә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең махсус рөхсәтеннән башка, шулай ук квота булып, аның күләмнәрен арттырып сатып алу, саклау, сату, җибәрү

Этил спиртын сатып алуга квотадан һәм Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкогольле продукциягә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең махсус рөхсәтеннән башка, шулай ук квота булып, аның күләмнәрен арттырып сатып алган, саклаган, сатқан, җибәргән өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең өч йөздән алып биш йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>5 статья.</u> Сату тыелган этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне сату

Сату тыелган этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне саткан өчен -

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>6 статья.</u> Тиешле үрнәктәге билгеләр белән тамгаланмаган алкогольле продукцияне сату

Тиешле үрнәктәге билгеләр белән тамгаланмаган алкогольле продукцияне саткан өчен -

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, алкогольле продук-

цияне конфискациялэп яисэ аннан тыш, хеэмэт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

7 статья. Алкоголь һәм алкогольле продукцияне билгеләнгән сәүдә нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып сату

Алкоголь һәм алкогольле продукцияне билгеләнгән сәүдә нормаларын һәм кагыйдәләрен бозып саткан өчен -

гражданнарга хезмәт өчен түләүнең илле минималь күләменә кадәр һәм предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

8 статья. Продукцияне җитештерүгә һәм әйләнешкә кертүгә тиешле лицензиясе булмаган җитештерүчедән яки күпләп сатучыдан алынган этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне сату

Продукцияне җитештерүгә һәм әйләнешкә кертүгә тиешле лицензиясе булмаган җитештерүчедән яки күпләп сатучыдан алынган этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне саткан өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкоголь продукциясен конфискациялэп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

9 статья. Сыйфат һәм куркынычсызлык, төрү һәм тамгалау буенча гамәлдәге норматив-техник документлар таләпләренә туры килмәгән, тиешле республика сертификаты яки аның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе булмаган, сертификат билгеләре белән тамгаланмаган (Татарстан Республикасына читтән кертелә торган алкоголь продукциясе өчен) этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештерү, сату

Сыйфат һәм куркынычсызлык, төрү һәм тамгалау буенча гамәлдәге норматив-техник документлар таләпләренә туры килмәгән, тиешле республика сертификаты яки аның билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе булмаган, сертификат билгеләре белән там-

90



галанмаган (Татарстан Республикасына читтән кертелә торган алкоголь продукциясе өчен) этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештергән, саткан өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп яисә аннан тыш, хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>10 статья.</u> Тиешле тәртиптә дәүләт теркәве үзмаган алкоголь продукциясен җитештерү һәм сату

Тиешле тәртиптә дәүләт теркәве үзмаган алкоголь продукциясен җитештергән һәм саткан өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен түләүнең йөздән алып өч йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

<u>11 статья.</u> Ялган алкоголь продукциясе җитештерү һәм (яисә) сату, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне ялган документлар буенча сату, алкоголь продукциясен ялган махсус һәм сертификация тамгалары белән сату

Ялган алкоголь продукциясе җитештергән һәм (яисә) саткан этил спиртын, алкоголь һәм алкоголь продукциясен ялган документлар буенча саткан, алкоголь продукциясен ялган махсус һәм сертификация тамгалары белән саткан өчен -

гражданнарга, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең өч йөздән алып биш йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

12 статья. Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тиешенчә рәсмиләштерелмәгән исәпкә алу, финанс һәм транспорт документларыннан башка сату

Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тиешенчә рәсмиләштерелмәгән исәпкә алу, финанс һәм транспорт документларыннан башка (аларда җитештерүче, сатучы, товарның сыйфаты, бәясе турында мәгълүмат булмаса), документларда мөһерләр, штамплар, имзалар һәм аларның аңлатмасы булмаган килеш саткан өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

13 статья. Тиешле тәртиптә рәсми исәпкә алынмаган этил спиртын, алкоголь продукциясен саклау һәм (яисә) сату

Этил спиртын һәм алкоголь продукциясен җитештерүче һәм (яисә) сатучы предприятиеләрдә тиешле тәртиптә рәсми исәпкә алынмаган этил спиртын һәм алкоголь продукциясен саткан өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә, этил спиртын һәм алкоголь продукциясен конфискацияләп, хезмәт өчен түләүнең ике йөздән алып өч йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

14 статья. Бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозу

Этил спиртына һәм алкоголь продукциясенә билгеләнгән күпләп сатып җибәрү, ваклап сату бәяләрен һәм сәүдә өстәмәләрен бозган өчен -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен түләүнең илледән алып йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**15 статья.** Спирт үлчәү, исәпләү приборларына яки этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция саклана торган урыннарга урындагы вәкаләтле зат салган мөһерне (пломбаны) бозу яисә алып ташлау

Спирт үлчәү, исәпләү приборларына яки этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукция саклана торган урыннарга урындагы вәкаләтле зат салган мөһерне (пломбаны) бозган яисә алып ташлаган өчен, -

предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренә, урындагы затларына, шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен түләүнең йөздән алып ике йөз минималь күләменә кадәр штраф салына.

**16 статья.** Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең күрсәтмәләрен үтәмәгән юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең җаваплылыгы

Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең:

- этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше нормаларын, кагыйдәләрен бозуны бетерү турындагы;
- этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештерүне һәм аларның әйләнешен туктатып тору турындагы;
- этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар бирү турындагы күрсәтмәләрне бозган өчен -

юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә хезмәт өчен минималь түләүнең биш мең тапкыр күләменә кадәр штраф салына.

17 статья. Этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция җитештерү һәм аларның әйләнеше өлкәсендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карауга вәкаләт бирелгән органнар (урындагы затлар)

Бу Законның 3 (1 һәм 3 өлешләр),4,5,6,8,9,11,12 һәм 13 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне - район (шәһәр) судлары; әлеге Законның 3 (2 өлеш), 7,10,14,15 һәм 16 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясе карый.

Әлеге Законның 3 (2 өлеш), 7,10,14 һәм 15 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр шулай ук Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең кулланучылар хокукларын яклау буенча территория (район, шәһәр) комитетлары каршындагы вәкаләтле территория органнары тарафыннан да карала.

Административ хокук бозулар турындагы эшләр Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясе исеменнән Дәүләт инспекциясе башлыгы яисә аның урынбасарлары тарафыннан; аның вәкаләтле территория органы исеменнән җитәкчесе яисә урынбасарлары тарафыннан карала.

18 статья. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр

Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитетының, аның территория (район, шәһәр) комитетларының, Татарстан Республикасының Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты каршындагы Татарстан Республикасының Алкоголь продукциясенә дәүләт монополиясен тәэмин итү дәүләт инспекциясенең, аның кулланучылар хокукларын яклау буенча

территория (район, шәһәр) комитетлары каршындагы территориаль органнарының, эчке эшләр органнарының, Татарстан Республикасы буенча Дәүләт салым инспекциясенең, Россия Федерациясе салым полициясенең Татарстан Республикасы буенча Федераль хезмәт идарәсенең шуңа вәкаләтле урындагы затлары тарафыннан түәелә.

19 статья. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау

Әлеге Законда каралган хокук бозу турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытта карала.

20 статья. Штрафлар суммасын бүлү

Әлеге Законның 3-15 статьяларында каралган штрафлар суммасы түбәндәгеләргә юнәлтелә: 25 проценты - хокук бозулар булган шәһәр һәм районнар бюджетына; 75 проценты - хокук бозуларны ачыклаган орган хисабына.

Бу Законның 16 статьясында каралган штрафлар суммасы Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

21 статья. Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тартып алу

Әлеге Законның 3-14 статьяларында күрсәтелгән хокук бозулар юлы белән житештерелгән һәм сатылган этил спирты, алкоголь һәм алкогольле продукция әлеге Законның 18 статьясында санап кителгән органнарның урындагы вәкаләтле затлары тарафыннан тартып алынырга мөмкин.

Этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тартып алганда беркетмә тутырыла яки административ хокук бозу турындагы беркетмәгә тиешенчә язып куела.

Тартып алынган продукциягә гамәлдәге норматив-техник документларда билгеләнгән куркынычсызлык таләпләренә туры килү буенча мәҗбүри экспертиза ясалырга тиеш һәм ул, эш каралганчыга кадәр, бу Законның 18 статьясында санап кителгән органнарның вәкаләтле затлары билгеләгән урыннарда сакланырга тиеш. Эш каралганнан соң, тартып алынган продукция, карау нәтиҗәләрен-

95



нән чыгып, билгеләнгән тәртиптә конфискацияләнә яисә хуҗасына кире кайтарып бирелә.

Тартып алынган продукцияне саклау, ташу, аңа мәҗбүри экспертиза үткәрү һәм аны юк итү белән бәйле чыгымнарны продукция хуҗасы түли.

Кызыксынучы затлар этил спиртын, алкоголь һәм алкогольле продукцияне тартып алуга тиешле тәртиптә шикаять белдерергә мөмкиннәр.

22 статья. Конфискацияләнгән продукциядән файдалануны дәвам итү

Дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирмәгән, кешеләр сәламәтлегенә һәм тормышына куркыныч тудырган конфискацияләгән продукция билгеләнгән тәртиптә юк ителергә тиеш.

Дәүләт стандартлары таләпләренә туры килмәгән, ләкин кешеләр сәламәтлегенә куркыныч тудырмаган конфискацияләнгән продукция промышленностьтә кабат эшкәртелергә тиеш.

Дәүләт стандартарының барлык таләпләренә дә туры килгән конфискацияләнгән продукция билгеләнгән тәртиптә сатыла.

Конфискацияләнгән продукцияне сатудан кергән акча, аны саклауга, ташуга, экспертизага, сатуга киткән чыгымнарны тотып калганнан соң, Татарстан Республикасының республика бюджетына җибәрелә.

23 статья. Әлеге Законны басылып чыккан көненнән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1997 елның 16 гыйнваре
N 1000